# «Чык тамчысы»

**Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы**
**"49 нчы санлы гомуми үстерелешле балалар бакчасы"**
**муниципаль үзидарә мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе**

***Ноябрь, 2022 ел***




***Хөрмәтле хезмәткәрләребез!***

Сезне Халыклар бердәмлеге көне белән ихлас күңелдән тәбрик итәбез! Илебез халкы өчен уртак булган әлеге бәйрәмнең тамыры Россия дәүләте барлыкка килү өчен иң мөһим шартлар тудырган ерак тарихка һәм вакыйгаларга барып тоташа.

Безнең һәрберебез үзенең киләчәген республика язмышы, үзе яши һәм эшли торган ил язмышы белән бәйли. Бүгенге Татарстан - ул Россия Федерациясенең иң куәтле сәнәгый һәм заманча алдынгы регионнарыннан берсе. Дини татулык һәм толерантлылыкның рухи нигезен киләчәктә дә ныгыту кирәклеген аңлап, без төрле халыкларның мәдәни байлыкларына һәм гореф-гадәтләренә ихтирамлы булырга, ил эчендә милләтара тотырыклылыкка янаган куркынычларга каршы актив каршы торырга тиешбез. Ватаныбызның лаеклы иртәгәсе, киләчәк буыннарның иминлеге хакына берләшеп, күпмилләтле илебезнең куәтен арттыруга, бөтендөнья икътисадында һәм сәясәттә туган катлаулы хәлдән чыгуга без лаеклы өлеш кертәбез. Безнең көч- бердәмлектә!

"Бердәмлектә көчле без!" девизы астында бакчабызда чаралар узды. Әти-әниләребез дә актив катнашты. Аларга зур рәхмәтләребезне җиткерәбез. Берә булыйк! Бердәм булыйк!











22 ноябрь көнне Ташлык авылы балалар бакчасында үзара эшчәнлек булып узды. Балаларның матур чыгышлары, "Халкым мирасы" мини-музеендагы экскурсия, педагогларның тирән эчтәлекле мастер-класслары, концерт номеры белән үрелеп барган әлеге чарадан һәркем үзенә кирәкле мәгълүмат алды.





Ел тәрбиячесе бәйгесенең чираттагы муниципаль этабында бакчабыз данын Вавилина Алена Виктор кызы һәм Галиуллина Рәзилә Ринат кызы яклады. Алар иҗади презентация, бердәм белем бирү эшчәнлеген татар һәи рус телләрендә күрсәттеләр. Уңышлар теләп калабыз. Афәрин!

25 нче ноябрь көнне бакчабыз хезмәткәрләре : мөдир Рәдинә Хайдарова, өлкән тәрбияче Айзирә Шакирянова, музыка җитәкчесе Вәсилә Мансурова диктант язарга "Заман" уку һәм аралашу үзәгенә җыелдылар. Нәтиҗәсен 21 нче декабрьдә шәхси кабинеттан кереп карарга мөмкин. Туган телебезне хөрмәт итик. Афәрин!






Балалар бакчасы эш нәтиҗәләре буенча чираттагы (бишенче) флаг алды, Халыкара Эко-мәктәп программасы кысаларында/Яшел флаг. Бу уку елында да эш дәвам итә.



25 ноябрьдә бакчабызда "Театр эшчәнлеге аша балаларда Рәсәй халкы мәдәниятенә, традицияләренә кызыксыну формалаштыру" исеме астында төбәкара семинар узды. Төбәгебезнең 8 районыннан (Түбән Кама, Яр Чаллы, Алабуга, Азнакай, Минзәлә, Әлмәт, Зәй, Чистай) 40 гариза кабул ителде. Катнашучылар саны, алар уртаклашкан тәҗрибә, яхшы тәкъдимнәр бу теманың актуаль икәнлеген күрсәтә. Яр Чаллы шәһәре 83 нче балалар бакчасының туган тел тәрбиячесе, "Татарча сөйләшәбез" методик кулланма авторы Кидрячева Раушания Гайнулла кызы да семинарда катнашып, "Яшь үсентеләр" исеме астында театр эшчәнлеге буенча программасын тәкъдим итте һәм семинарны оештыру буенча уңай бәя бирде. Тәҗрибәләр белән уртаклашып, аралашып балаларыбызга тәрбия бирүдә яхшы күрсәткечләргә ирешергә язсын. Бергә булыйк! Бердәм булыйк!









Әни - җир йөзендәге иң кадерле, иң матур сүз. Ул барлык телләрдә дә бердәй әһәмиятле һәм аһәңле яңгырый. Йөрәге астында яралган һәр сабыйга җан өрүче, җирдә яшәү бәхетен бүләк итүче, төн йокыларын калдырып кадерләп багып үстерүче, соңгы телем икмәген дә балаларына бирергә тырышучы, үзе туңганда да газиз нарасыен - йөрәк парәсен җылыта алучы әниләребезнең һәркайсы алиһәләргә тиң затлар. Без гомер буена әниләребезгә бурычлы булып калабыз, аларның тормышын ямьләп, һәрвакыт хәстәрләп яшәргә телибез. Районыбызда гомер кичерүче барлык хатын-кызларыбызны – балалары-оныклары өчен өлге булып яшәүче хөрмәтле картәниләр, гаиләдә дә, эш урыннарында да өлгеле әниләр һәм киләчәктә гаилә корып, әни булу бәхетенә ирешәчәк кызларны ихлас йөрәктән Әниләр көне белән кайнар котлап, һәммәгезгә дә ныклы сәламәтлек, иминлек, бәхетле, бәрәкәтле җитеш тормыш, иң ихтирамлы, иң хөрмәтле кешеләр булып, шатлык-сөенечләр кичереп кенә яшәвегезне телим. Якыннарыгыз сезгә гел куанычлар гына китерсен, һәр көнегез бәрәкәт- җитешлектә ирешелгән уңышлар, тормышка ашкан хыяллар, шат күңел белән үтсен. Һәммәгезгә дә тынычлыкта ак бәхетләр кичереп яшәү насыйп булсын!

Бакчабызда әниләр көненә багышланган "Һәрвакыт булсын әни!" әдәби-музыкаль чарасы гөрләп узды." Әниемнең алтын куллары" кул эшләре күргәзмәсе оештырылды.








"Без аерым чүп җыю өчен", "Росинка" командасы өчен "ЭкоДети-2022" республика конкурсында катнашучыларга икенче бирем шулай аталды. Балалар тәрбияче белән бергә әкият персонажы рәвешендә контейнер әзерләделәр, экоакция оештырдылар, анда ата-аналар һәм балалар бакчасы хезмәткәрләре актив катнашты.





**Хөрмәтле хезмәткәрләребез!**

**Максимова Зинаида Петр кызы**

**Саметова Регина Илис кызы**

**Насретдинова Зөлфия Минзагит кызы**

**Сапожникова Светлана Владимир кызы**




Көчле рухлы һәм кешелекле, юмарт һәм ярдәмчел, бәхетле һәм сәламәт булыгыз! Ныклы тазалык, озын гомер, ак бәхетләр белән мул тормышта яшәвегезне телибез.